КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 23 февраль г.Казань № 176

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» 2005 ел, 22 гыйнвар, 20 нче карары белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» 2005 ел, 22 гыйнвар, 20 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 30 май, 245 нче; 2005 ел, 17 ноябрь, 539 нчы; 2006 ел, 16 ноябрь, 547 нче; 2007 ел, 5 февраль, 33 нче; 2007 ел, 28 март, 113 нче; 2007 ел, 13 июль, 295 нче; 2008 ел, 31 гыйнвар, 48 нче; 2008 ел, 12 март, 157 нче; 2008 ел, 29 май, 344 нче; 2009 ел, 4 февраль, 64 нче; 2009 ел, 21 сентябрь, 654 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2013 ел, 21 октябрь, 781 нче; 2015 ел, 3 июль, 483 нче; 2015 ел, 22 август, 612 нче; 2015 ел, 30 декабрь, 1033 нче; 2016 ел, 9 март, 132 нче; 2016 ел, 13 май, 306 нчы; 2016 ел, 7 июль, 462 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 998 нче; 2017 ел, 7 август, 562 нче; 2019 ел, 13 март, 181 нче; 2019 ел, 13 июнь, 490 нчы; 2019 ел, 2 сентябрь, 749 нчы; 2019 ел, 20 декабрь, 1173 нче; 2021 ел, 15 февраль, 80 нче, 2021 ел, 30 декабрь, 1354 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

унҗиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге (алга таба - Татарстан Республикасы буенча ПСИФБ) (килешү буенча);»;

унсигезенче  абзац үз көчен югалткан дип танырга;

егерме беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия почтасы» акционер җәмгыятенең «Татарстан почтасы» федераль почта элемтәсе идарәсе (алга таба - «Татарстан почтасы» ФПЭИ (килешү буенча);»;

6 пункт таблицасының 9  пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «9. | ТР буенча ОФПСС | Тапшыру: исәпләнгән пенсияләр, ай саен өстәмә матди тәэмин итү, хезмәткә сәләтсез гражданнарны тәрбияләүче затларга компенсация түләүләре турында мәгълүмат | электрон | агымдагы айның 15 числосына кадәр | ТР ХЭТһСЯМ». |
| | | Советлар Союзы Геройларының, Россия Федерациясе Геройларының, Дан орденының тулы кавалерларының һәм аларның гаилә әгъзаларының федераль мәгълүматлар базасының төбәк сегменты белешмәләре | | хисап аеннан соң килә торган айның 10 ысына кадәр | |
| | | Социаль хезмәтләр җыелмасы рәвешендә дәүләт социаль ярдәмен алу хокукы булган затлар федераль регистрының төбәк сегменты белешмәләре | | хисап аеннан соң килүче айның 10 числосына кадәр һәм айның 20 сенә кадәр | |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин